**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2015 ел, 1 декабрь | № 911

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2004 ел, 17 декабрь, 542 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 22 гыйнвар, 22 нче; 2005 ел, 30 май, 239 нчы; 2006 ел, 2 октябрь, 490 нчы; 2007 ел, 6 апрель, 123 нче; 2008 ел, 8 сентябрь, 640 нчы; 2010 ел, 29 ноябрь, 956 нчы; 2011 ел, 21 июнь, 496 нчы; 2011 ел, 6 декабрь, 1001 нче; 2012 ел, 13 апрель, 304 нче; 2013 ел, 19 гыйнвар, 20 нче; 2013 ел, 12 март, 157 нче; 2014 ел, 8 февраль, 80 нче; 2014 ел, 5 декабрь, 947 нче; 2015 ел, 15 апрель, 254 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«пенсияләре «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» федераль законнар нигезендә билгеләнгән, Татарстан Республикасында яшәүче, мөрәҗәгать итү көнендә уртача айлык керемнәре күләме 20 000 мең сумнан артмаган, Россия Федерациясе һәм (яки) Татарстан Республикасының бүтән норматив хокукый актлары нигезендә социаль ярдәм чараларына хокуклары булмаган пенсионерларга юл йөрергә айлык акчалата түләү бирелә, 2016 елда аның күләме 427 сум булачак;»;

түбәндәге эчтәлекле яңа абзац өстәргә:

«пенсияләре «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» федераль законнар нигезендә билгеләнгән, Татарстан Республикасында яшәүче, мөрәҗәгать итү көнендә уртача айлык керемнәре күләме 20 000 мең сумнан артмаган, Россия Федерациясе һәм (яки) Татарстан Республикасының бүтән

норматив хокукый актлары нигезендә социаль ярдәм чараларына хокуклары булмаган пенсионерларга юл йөрергә айлык акчалата түләү бирелә, 2016 елда аның күләме 280 сум, ә 2017 елда – 180 сум булачак;»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәдә:

1.1 пунктның унөченче абзацында «телефон өчен абонент түләве буенча» сүзләрен «абонентка даими файдалануга бирелгән теркәлгән телефон элемтәсе челтәренең абонент линиясе өчен түләү буенча» сүзләренә алмаштырырга;

2 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Айлык акчалата түләүне бирү тәртибе

2.1. Айлык акчалата түләү түбәндәгеләргә билгеләнә һәм түләнә:

1941 елның 22 июненнән 1945 елның 9 маена кадәр кимендә алты ай тылда эшләгән затларга (СССРның вакытлыча оккупацияләнгән территорияләрендә эшләгән чорны кертмичә); Бөек Ватан сугышы чорында фидакарь хезмәт өчен СССР орденнары һәм медальләре белән бүләкләнгән затларга;

пенсияләре «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» федераль законнар нигезендә билгеләнгән хезмәт ветераннарына, шулай ук башка нигезләр буенча пенсия алучы яки эшләгән (хезмәт иткән) өчен «Иминият пенсияләре турында» Федераль законның 8 статьясындагы беренче өлеш нигезендә картлык буенча иминият пенсиясенә хокук бирә торган яшькә җиткәннән соң гомер буе түләнә торган акча алучы, мөрәҗәгать итү көнендә уртача айлык керемнәре күләме 20 000 мең сумнан артмаган хезмәт ветераннарына (алга таба – хезмәт ветераннары);

реабилитацияләнгән гражданнарга;

сәяси репрессияләрдән зыян күргән гражданнарга;

«Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» Татарстан Республикасы Законы белән билгеләнгән Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләнгән, пенсияләре «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» федераль законнар нигезендә билгеләнгән затларга, шулай ук «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» Татарстан Республикасы Законы белән гамәлгә куелган Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләнгән, башка нигезләр буенча пенсия алучы яки эшләгән (хезмәт иткән) өчен «Иминият пенсияләре турында» Федераль законның 8 статьясындагы беренче өлеш нигезендә картлык буенча пенсиягә хокук бирә торган яшькә җиткәннән соң гомер буе түләнә торган акча алучы затларга (алга таба – «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» Татарстан Республикасы Законы белән билгеләнгән Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләнгән затлар).

Әгәр дә граждан бер үк вакытта «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законы буенча

һәм федераль закон яки башка норматив хокук акты буенча айлык акчалата түләүгә, аны билгеләү нигезләмәсе («Чернобыль АЭСында фаҗига аркасында радиация тәэсиренә дучар ителгән гражданнарны социаль яклау турында» Россия Федерациясе Законы, «Семипалатинск полигонында атом-төш сынаулары аркасында радиация тәэсиренә дучар ителгән гражданнарга социаль гарантияләр турында» Федераль закон нигезендә айлык акчалата түләү билгеләү очракларыннан тыш) нинди булуга карамастан, хокуклы булса, аңа бер айлык акчалата түләү, граждан сайлавына карап, йә «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законы буенча йә федераль закон яки башка норматив хокук акты буенча гамәлгә ашырыла.

2.2. Айлык акчалата түләү билгеләү өчен бу Нигезләмәнең 2.1 нче пунктында күрсәтелгән гражданнар, аларның законлы вәкилләре яки алар ышанычнамә нигезендә вәкаләт биргән затлар Үзәкнең үзләре яшәгән урындагы бүлегенә түбәндәгеләрне кертә:

айлык акчалата түләү билгеләү турында гариза, ул электрон укыла торган имзадан файдаланып имзаланырга мөмкин;

затның бу Нигезләмәнең 2.1 нче пунктында күрсәтелгән гражданнар категориясенә каравын раслый торган документлар күчермәләрен;

айлык акчалата түләү билгеләү өчен гариза бу Нигезләмәнең 2.1 нче пунктында күрсәтелгән гражданның ышанычлы заты тарафыннан кертелгәндә, Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычнамә (алга таба – ышанычнамә) күчермәсен.

Хезмәт ветераннары өстәмә рәвештә айлык акчалата түләү бирү турында мәсьәләне хәл иткәндә исәпкә алына торган аларның керемнәрен раслаган документлар тапшырырга хокуклы. Хезмәт ветеранына айлык акчалата түләү билгеләү өчен уртача айлык керемне исәпләгәндә исәпкә алына торган керемнәр төрләре исемлеге әлеге Нигезләмәгә кушымтада күрсәтелгән.

Әгәр мөрәҗәгать иткән көндә хезмәт ветераны торак урын һәм коммуналь хезмәтләргә түләүгә субсидия (алга таба – субсидия) алучы булып тора икән, айлык акчалата түләү Үзәк бүлегендә булган аның керемнәре турында мәгълүматлар нигезендә билгеләнә.

Документлар күчермәләре нотариуста яки органда (документның төп нөсхәсен биргән оешмада, учреждениедә) таныкланмаган очракта, алар төп нөсхәләрне күрсәтеп тапшырыла һәм Үзәк бүлеге белгече тарафыннан раслана.

Бу Нигезләмәнең 2.1 нче пунктында күрсәтелгән гражданнар, аларның законлы вәкилләре яки алар ышанычнамә нигезендә вәкаләт биргән затлар гариза белән мөрәҗәгать иткәндә гариза бирүченең шәхесен таныклаучы документ күрсәтә һәм банкта яки бүтән кредит оешмасында ачылган шәхси исәп счеты реквизитларын бирә.

2.3. Үзәк бүлеге айлык акчалата түләүне гамәлгә ашыру турында карар кабул итү өчен ведомствоара сораулар нигезендә (шул исәптән, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасыннан файдаланып, электрон рәвештә) түбәндәге кирәкле мәгълүматлар соратып ала:

вәкаләтле оешмалардан «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт

пенсия тәэминаты турында» федераль законнар нигезендә пенсия билгеләү турында мәгълүматлар;

вәкаләтле оешмалардан федераль законнар нигезендә айлык акчалата түләүне алудан баш тарту турында мәгълүматлар.

2.4. Айлык акчалата түләүне алу максатларында, бу Нигезләмәнең 2.1 нче пунктында күрсәтелгән гражданнар, аларның законлы вәкилләре яки алар ышанычнамә нигезендә вәкаләт биргән затлар үз башлангычлары белән Үзәк бүлегенә бу Нигезләмәнең 2.3 нче пунктында күрсәтелгән мәгълүматлар бирелгән документларны кертергә хокуклы.

2.5. Бу Нигезләмәнең 2.2 нче пунктындагы кертелгән документлар, бу Нигезләмәнең 2.3 нче пунктында күрсәтелгән мәгълүматлар нигезендә Үзәк бүлеге кирәкле барлык документлар белән бергә айлык акчалата түләү билгеләү турында гариза теркәлгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә айлык акчалата түләү билгеләү турында яисә аны билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итә һәм кабул ителгән карар турында гариза бирүчегә гаризада күрсәтелгән ысул (почта адресы буенча хат рәвешендә, электрон почта адресы буенча электрон документ рәвешендә, телефонга смс-хәбәр белән, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында шәхси кабинет аша) белән хәбәр итә.

Айлык акчалата түләү билгеләүдән баш тарту өчен бу Нигезләмәнең 2.2 нче пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмау нигез була.

2.6. Әлеге Нигезләмәнең 2.1 пунктында күрсәтелгән гражданнарга (хезмәт ветераннарыннан тыш) айлык акчалата түләү барлык кирәкле документлары белән гариза бирелгән айдан башлап билгеләнә һәм түләнә.

Хезмәт ветераннарына айлык акчалата түләү барлык кирәкле документлары белән гариза бирелгән айдан башлап билгеләнә һәм билгеләнгән айдан башлап алты ай дәвамында түләнә.

Мөрәҗәгать иткән көндә хезмәт ветераны субсидия алучы булса, айлык акчалата түләү субсидия бирү вакыты тәмамланганга кадәр түләнә.

Әгәр хезмәт ветераны субсидия билгеләүне сорап мөрәҗәгать иткән граждан гаиләсе әгъзасы составына керә икән, субсидия билгеләү турында гариза белән бергә айлык акчалата түләү билгеләү турында гариза да бирелергә мөмкин. Айлык акчалата түләү субсидия алучы тапшырган гаилә кереме турында документларны исәпкә алып, субсидия алу чорында түләнә.

2.7. Айлык акчалата түләүне гамәлгә ашыру аны түләүне туктатуга китерә торган шартлар барлыкка килгән айдан соң килүче айдан башлап туктатыла.

Айлык акчалата түләүне гамәлгә ашыруны туктату өчен нигез булып түбәндәгеләр тора:

айлык акчалата түләүне алуга хокуклы граждан вафат булган;

айлык акчалата түләүне алуга хокуклы граждан үлгән яки кайда икәне билгесез булган дип билгеләнгән тәртиптә танылган;

граждан айлык акчалата түләүне алу хокукын югалткан;

айлык акчалата түләүне алуга хокуклы граждан яшәү урынын алыштырган.

2.8. Айлык акчалата түләү билгеләү өчен уртача айлык керем хезмәт ветеранына барлык кирәкле документлары белән айлык акчалата түләү билгеләү

турында гариза тапшырган айга кадәрге соңгы алты календарь ай өчен билгеләнә (алга таба – исәп чоры).

2.9. Уртача айлык керем аның исәп чоры дәвамында алынган керемнәре суммасын ул әлеге керемнәрне алган бу исәп чоры айлары санына бүлү юлы белән билгеләнә.

2.10. Үзәк бүлекләренә Россия Федерациясе Пенсия фондыннан, шул исәптән бердәм ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасыннан һәм аңарга тоташтырылган төбәк ведомствоара электрон хезмәттәшлек системаларыннан файдаланып эш бирүче (иминиятләүче) физик зат файдасына күчергән түләүләр һәм бүтән бүләкләүләр суммасы турында мәгълүмат алу мөмкинлеген биргән мәгълүмати багланышларны керткәннән соң, хезмәт ветеранына айлык акчалата түләүне билгеләү аның гаризада күрсәтелгән ризалыгы белән, хезмәт ветераны айлык акчалата түләүне сорап мөрәҗәгать иткән айга кадәрге 12 айның соңгы алты аена Россия Федерациясе Пенсия фондында булган мәгълүматлар нигезендә башкарыла.

2.11. Үзәк бүлегендә хезмәт ветеранының айлык акчалата түләүне алуга хокукын раслый торган белешмәләр булганда, аңа яңа вакытка айлык акчалата түләү хезмәт ветераны мөрәҗәгатеннән башка, автомат рәвештә билгеләнә;

хезмәт ветераны айлык акчалата түләүне алуга хокукын югалткан очракта, аның гаризада күрсәтелгән ризалыгы белән юл йөрергә айлык акчалата түләү билгеләнергә мөмкин, аның зурлыгы 2016 елда аның күләме 280 сум, ә 2017 елда – 180 сум булачак.»;

7 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Элемтә хезмәтләренә субсидия билгеләү һәм түләү тәртибе

7.1. Элемтә хезмәтләренә субсидия түбәндәгеләргә билгеләнә һәм түләнә:

хезмәт ветераннарына;

«Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» Татарстан Республикасы Законы белән билгеләнгән Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләнгән затларга.

7.2. Элемтә хезмәтләренә субсидия алу өчен бу Нигезләмәнең 7.1 нче пунктында күрсәтелгән гражданнар, аларның законлы вәкилләре яки алар ышанычнамә нигезендә вәкаләт биргән затлар Үзәкнең үзләре яшәгән урындагы бүлегенә түбәндәгеләрне кертә:

элемтә хезмәтләренә субсидия билгеләү турында гариза;

затның бу Нигезләмәнең 7.1 нче пунктында күрсәтелгән гражданнар категориясенә каравын раслый торган документлар күчермәләрен;

элемтә хезмәтләренә субсидия билгеләү өчен гариза ышанычлы зат тарафыннан кертелгәндә, ышанычнамә күчермәсен.

Хезмәт ветераннары өстәмә рәвештә айлык акчалата түләү бирү турында мәсьәләне хәл иткәндә исәпкә алына торган аларның керемнәрен раслаган документлар тапшырырга хокуклы. Хезмәт ветеранына айлык акчалата түләү билгеләү өчен уртача айлык керемне исәпләгәндә исәпкә алына торган керемнәр төрләре исемлеге әлеге Нигезләмәгә кушымтада күрсәтелгән.

Документлар күчермәләре нотариуста яки органда (документның төп нөсхәсен биргән оешмада, учреждениедә) таныкланмаган очракта, алар төп нөсхәләрне күрсәтеп тапшырыла һәм Үзәк бүлеге белгече тарафыннан раслана.

Бу Нигезләмәнең 2.1 нче пунктында күрсәтелгән гражданнар, аларның законлы вәкилләре яки алар ышанычнамә нигезендә вәкаләт биргән затлар гариза белән мөрәҗәгать иткәндә гариза бирүченең шәхесен таныклаучы документ күрсәтә һәм банкта яки бүтән кредит оешмасында ачылган шәхси исәп счеты реквизитларын бирә.

7.3. Үзәк бүлеге элемтә хезмәте күрсәтүләргә субсидия бирү турында карар кабул итү өчен ведомствоара сораулар нигезендә (шул исәптән, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасыннан файдаланып, электрон чыганакта) түбәндәге кирәкле мәгълүматлар соратып ала:

вәкаләтле оешмалардан «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» федераль законнар нигезендә пенсия билгеләү турында белешмә кәгазен;

вәкаләтле оешмалардан федераль законнар нигезендә айлык акчалата түләүне алудан баш тарту турында белешмә кәгазен;

бу Нигезләмәнең 7.1 нче пунктында күрсәтелгән гражданнарның элемтә операторларыннан чыбыклы телефон элемтәсе булуы турында белешмә кәгазен.

7.4. Элемтә хезмәтләренә субсидия алу максатында бу Нигезләмәнең 7.1 нче пунктында күрсәтелгән гражданнар, аларның законлы вәкилләре яки алар ышанычнамә нигезендә вәкаләт биргән затлар үз башлангычлары белән Үзәк бүлегенә бу Нигезләмәнең 7.3 нче пунктында күрсәтелгән мәгълүматлар бирелгән документларны кертергә хокуклы.

7.5. Хезмәт ветераннарына Элемтә хезмәтләренә субсидия билгеләгәндә исәпкә алына торган керемнәрне исәпкә алу һәм уртача айлык керемне исәпләү тәртибе бу Нигезләмәнең 2 бүлегендәге 2.8 – 2.10 нчы пуктларда билгеләнгән хезмәт ветераннарына айлык акчалата түләү билгеләгәндә керемнәрне исәпкә алу һәм уртача айлык керемне исәпләү тәртибе кебек үк.

7.6. Бу Нигезләмәнең 7.2 нче пунктындагы кертелгән документлар, бу Нигезләмәнең 7.3 нче пунктында күрсәтелгән мәгълүматлар нигезендә Үзәк бүлеге кирәкле барлык документлар белән бергә айлык акчалата түләү билгеләү турында гариза теркәлгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә айлык акчалата түләү билгеләү турында яисә аны билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итә һәм кабул ителгән карар турында бу Нигезләмәнең 7.1 нче пунктында күрсәтелгән гражданнарга гаризада күрсәтелгән ысул (почта адресы буенча хат рәвешендә, электрон почта адресы буенча электрон документ рәвешендә, телефонга смс-хәбәр белән, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында шәхси кабинет аша) белән хәбәр итә.

Айлык акчалата түләү билгеләүдән баш тарту өчен бу Нигезләмәнең 7.2 нче пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмау, бу Нигезләмәнең 7.1 нче пунктында күрсәтелгән гражданнарның чыбыклы телефон элемтәсе булмау нигез була.

7.7. Элемтә хезмәтләренә субсидия гариза биргән айдан билгеләнә һәм билгеләнү аеннан башлап алты ай дәвамында түләнә.

7.8. Үзәк бүлегендә хезмәт ветеранының элемтә хезмәтләренә субсидия алуга хокукын раслый торган белешмәләр булганда, аңа яңа вакытка элемтә хезмәтләренә субсидия хезмәт ветераны мөрәҗәгатеннән башка, автомат рәвештә билгеләнә.

7.9. Элемтә хезмәтләренә субсидия бирү аны алуга хокуклы граждан вафат булган, аны үлгән яки кайда икәне билгесез булган дип билгеләнгән тәртиптә таныган очракта, граждан элемтә хезмәтләренә субсидия алуга хокукын югалткан, яшәү урынын алыштырган очракта, тиешле вакыйгалар килеп чыккан айдан соң килүче айдан башлап туктатыла.»;

9 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Транспортта йөрүгә айлык акчалата түләүне
билгеләү һәм түләү тәртибе

9.1. Транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләү өчен пенсияләре «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» федераль законнар нигезендә билгеләнгән, Россия Федерациясенең һәм (яки) Татарстан Республикасының башка норматив хокук актлары буенча социаль ярдәм чаралары күрсәтүгә хокукы булмаган, Татарстан Республикасында яши торган пенсионерлар яки алар ышанычнамә нигезендә вәкаләт биргән затлар (алга таба – пенсионерлар), аларның законлы вәкилләре яки алар ышанычнамә нигезендә вәкаләт биргән затлар (алга таба – гариза бирүчеләр) Үзәкнең үзләре яшәгән урындагы бүлегенә түбәндәгеләрне кертә:

транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләү турында гариза;

транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләү өчен гариза ышанычлы зат тарафыннан кертелгәндә, ышанычнамә күчермәсен.

Пенсионерлар ирекле рәвештә транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү бирү турында мәсьәләне хәл иткәндә исәпкә алына торган аларның керемнәрен раслаган документлар тапшырырга хокуклы. Пенсионерларга транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләү өчен уртача айлык керемне исәпләгәндә исәпкә алына торган керемнәр төрләре исемлеге әлеге Нигезләмәгә кушымтада күрсәтелгән.

Әгәр мөрәҗәгать иткән көндә пенсионер субсидия алучы булып тора икән, айлык акчалата түләү Үзәк бүлегендә булган аның керемнәре турында мәгълүматлар нигезендә билгеләнә.

Документлар күчермәләре нотариуста яки органда (документның төп нөсхәсен биргән оешмада, учреждениедә) таныкланмаган очракта, алар төп нөсхәләрне күрсәтеп тапшырыла һәм Үзәк бүлеге белгече тарафыннан раслана.

Гариза бирүчеләр гариза белән мөрәҗәгать иткәндә гариза бирүченең шәхесен таныклаучы документ күрсәтә һәм банкта яки бүтән кредит оешмасында ачылган шәхси исәп счеты реквизитларын бирә.

9.2. Үзәк бүлеге айлык акчалата түләүне гамәлгә ашыру турында карар кабул итү өчен ведомствоара сораулар нигезендә (шул исәптән, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасыннан файдаланып, электрон рәвештә) вәкаләтле

оешмалардан «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» федераль законнар нигезендә билгеләү турында мәгълүматлар соратып ала.

9.3. Транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү алу максатында гариза бирүчеләр үз башлангычлары белән Үзәк бүлегенә бу Нигезләмәнең 7.3 нче пунктында күрсәтелгән мәгълүматлар бирелгән документларны кертергә хокуклы.

9.4. Бу Нигезләмәнең 9.1 нче пунктындагы кертелгән документлар, бу Нигезләмәнең 9.2 нче пунктында күрсәтелгән мәгълүматлар нигезендә Үзәк бүлеге кирәкле барлык документлар белән бергә транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләү турында гариза теркәлгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләү турында яисә аны билгеләүдән баш тарту хакында карар кабул итә һәм кабул ителгән карар турында бу гариза бирүчеләргә гаризада күрсәтелгән ысул (почта адресы буенча хат рәвешендә, электрон почта адресы буенча электрон документ рәвешендә, телефонга смс-хәбәр белән, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында шәхси кабинет аша) белән хәбәр итә.

Айлык акчалата түләү билгеләүдән баш тарту өчен бу Нигезләмәнең 9.1 нче пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмау нигез була.

9.5. Транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү барлык кирәкле документлары белән гариза бирелгән айдан башлап билгеләнә һәм билгеләнгән айдан башлап алты ай дәвамында түләнә. Гариза бирүче 2016 елның февралендә социаль яклау органнары раслаган график буенча мөрәҗәгать иткәндә транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү 2016 елның 1 гыйнварыннан билгеләнә.

Әгәр пенсионер субсидия билгеләүне сорап мөрәҗәгать иткән граждан гаиләсе әгъзасы составына керә икән, субсидия билгеләү турында гариза белән бергә транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләү турында гариза да бирелергә мөмкин. Транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү субсидия алучы тапшырган гаилә кереме турында документларны исәпкә алып, субсидия алу чорында түләнә.

Мөрәҗәгать иткән көндә пенсионер субсидия алучы булса, транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү субсидия бирү вакыты тәмамланганга кадәр түләнә.

Үзәк бүлегендә пенсионерның айлык акчалата түләүне алуга хокукын раслый торган белешмәләр булганда, аңа яңа вакытка айлык акчалата түләү пенсионер мөрәҗәгатеннән башка, автомат рәвештә билгеләнә.

9.6. Транспортта йөрүгә айлык акчалата түләүне гамәлгә ашыру аны түләүне туктатуга китерә торган шартлар барлыкка килгән айдан соң килүче айдан башлап туктатыла.

Транспортта йөрүгә айлык акчалата түләүне гамәлгә ашыруны туктау өчен нигез булып түбәндәгеләр тора:

транспортта йөрүгә айлык акчалата түләүне алуга хокуклы граждан вафат булган;

транспортта йөрүгә айлык акчалата түләүне алуга хокуклы граждан үлгән яки кайда икәне билгесез булган дип билгеләнгән тәртиптә танылган;

граждан транспортта йөрүгә айлык акчалата түләүне алу хокукын югалткан;

транспортта йөрүгә айлык акчалата түләүне алуга хокуклы граждан яшәү урынын алыштырган.

9.7. Транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләү өчен уртача айлык керемне исәпләгәндә исәпкә алына торган керемнәр төрләре исемлеге әлеге Нигезләмәгә кушымтада күрсәтелгән.

9.9. Танспортта йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләү өчен уртача айлык керем пенсионерга барлык кирәкле документлары белән транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләү турында гариза тапшырган айга кадәрге соңгы алты календарь ай өчен билгеләнә (алга таба – исәп чоры).

9.10. Уртача айлык керем пенсионерның исәп чоры дәвамында алынган керемнәре суммасын ул әлеге керемнәрне алган бу исәп чоры айлары санына бүлү юлы белән билгеләнә.

9.11. Үзәк бүлекләренә Россия Федерациясе Пенсия фондыннан, шул исәптән бердәм ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасыннан һәм аңарга тоташтырылган төбәк ведомствоара электрон хезмәттәшлек системаларыннан файдаланып эш бирүче (иминиятләүче) физик зат файдасына күчергән түләүләр һәм бүтән бүләкләүләр суммасы турында мәгълүмат алу мөмкинлеген биргән мәгълүмати багланышларны керткәннән соң, пенсионерга транспортта йөрүгә айлык акчалата түләүне билгеләү аның гаризада күрсәтелгән ризалыгы белән, пенсионер транспортта йөрүгә айлык акчалата түләүне сорап мөрәҗәгать иткән айга кадәрге 12 айның соңгы алты аена Россия Федерациясе Пенсия фондында булган мәгълүматлар нигезендә башкарыла.»;

Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге эчтәлекле кушымта өстәргә:

«Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә кушымта

Хезмәт ветераннарына һәм пенсионерларга социаль ярдәм чараларын күрсәткәндә исәпкә алынган

КЕРЕМНӘР ТӨРЛӘРЕ

1. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Уртача хезмәт хакын исәпләү тәртибе үзенчәлекләре турында» 2007 ел, 24 декабрь, 922 нче карары нигезендә уртача хезмәт хакын исәпләгәндә исәпкә алына торган, хезмәткә түләү системасында каралган барлык түләүләр;

хезмәт законнарында күздә тотылган очракларда саклanган уртача хезмәт хакы;

дәүләт яки иҗтимагый йөкләмәләрне башкарганда дәүләт органы яки иҗтимагый оешма түләгән компенсация;

эштән чыкканда түләнелә торган чыгу пособиесе, отставкага чыкканда компенсация, оешманың ябылуы, хезмәткәрләр саны яки штаты кимү белән бәйле эштән чыкканда эшкә урнашу чорына саклана торган эш хакы;

Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә төзелгән шартнамәләр буенча эшләргә түләү;

эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шөгыльләнүдән керемнәр, крестьян (фермер) хуҗалыгы, шул исәптән юридик зат оештырмаган хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәсендә алынган керемнәрне дә кертеп.

2. Барлык дәрәҗәдәге бюджетлардан социаль түләүләр:

пенсияләр, компенсация түләүләре (өстәмәләр, өстәп түләүләр);

пенсионерларны өстәмә айлык матди тәэмин итү;

ирекле иминиятләү шартларында түләнә торган өстәмә пенсияләр, дәүләтнеке булмаган пенсия фондларыннан түләнә торган пенсияләрне дә кертеп;

отставкага чыккан судьяларга айлык гомер буе түләнә торган акча;

ятим балаларга, ятим балалар арасыннан булган затларга, инвалид балаларга һәм инвалидларга стипендия;

эшсезлек буенча пособие;

матди ярдәм суммалары (эшсезләргә, студентларга, эшләүчеләргә);

һөнәри укыту яки яңадан укыту чорында алына торган стипендияләр суммалары;

эш белән тәэмин итү хезмәте органнары җибәрүе буенча иҗтимагый яки вакытлыча эшләрдә катнашкан гражданнарга аларның катнашу чорында законнарда каралган түләүләр (матди ярдәм);

14 яшьтән 18 яшькәчә балигъ булмаган гражданнарның вакытлыча эшләрдә катнашу чорында аларга түләүләр (матди ярдәм);

вакытлыча эшкә яраксыз булу буенча пособие;

җитештерүдәге бәхетсез очраклардан һәм һөнәри авырулардан мәҗбүри социаль иминиятләү буенча айлык иминият түләүләре;

оешмалар белән наем шартларында хезмәт мөнәсәбәтләрендә торган, бала тәрбияләү буенча ялда булган гражданнарга айлык компенсация түләүләре.

3. Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар билгеләгән бүтән социаль түләүләр, шул исәптән:

Чернобыль фаҗигасе сәбәпле нурланыш тәэсире яисә Чернобыль АЭСта авария нәтиҗәләрен бетерү буенча эшләр башкару белән бәйле гражданнар сәламәтлегенә китерелгән зыянны кайтаруга айлык акчалата компенсация;

хәрби хезмәткәрнең яки хәрби җыеннарга чакырылган гражданның хәрби хезмәт вазыйфаларын үтәгәндә вафат булуы (үлеме) яисә хәрби җәрәхәттән үлүе очрагында гаиләнең һәр әгъзасына түләнә торган айлык акчалата компенсация.».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү турында» 2006 ел, 24 март, 126 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 3 июнь, 370 нче; 2009 ел, 6 апрель, 203 нче; 2010 ел, 13 июль, 553 нче; 2012 ел, 23 февраль, 153 нче; 2013 ел, 12 март, 157 нче; 2014 ел, 25 август, 611 нче; 2015 ел, 23

сентябрь, 701 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәдә:

2.2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә ТКХ түләү буенча социаль ярдәм чараларына хокуклы хезмәт ветераннары (алга таба – хезмәт ветераннары) өстәмә рәвештә субсидия-ташламалар бирү турында мәсьәләне хәл иткәндә исәпкә алына торган керемнәрен раслаган документлар тапшырырга хокуклы. Хезмәт ветеранына субсидия-ташлама билгеләү өчен уртача айлык керемне исәпләгәндә исәпкә алына торган керемнәр төрләре исемлеге әлеге Нигезләмәгә кушымтада күрсәтелгән.

Әгәр мөрәҗәгать иткән көндә хезмәт ветераны торак урын һәм коммуналь хезмәтләргә түләүгә субсидия (алга таба – субсидия) алучы булып тора икән, субсидия-ташлама Үзәк бүлегендә булган аның керемнәре турында мәгълүматлар нигезендә билгеләнә.

Үзәк бүлеге элемтә хезмәте күрсәтүләргә субсидия бирү турында карар кабул итү өчен ведомствоара сораулар нигезендә (шул исәптән, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасыннан файдаланып, электрон чыганакта) түбәндәге кирәкле мәгълүматлар соратып ала:

вәкаләтле оешмалардан «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» федераль законнар нигезендә пенсия билгеләү турында белешмә кәгазен;

вәкаләтле оешмалардан федераль законнар нигезендә айлык акчалата түләүне алудан баш тарту турында белешмә кәгазен;

вәкаләтле оешмалардан законнар нигезендә, даими яшәү урыны буенча ТКХ түләү буенча социаль ярдәм чараларына хокуклы гражданнар белән бергә теркәлгән гражданнар турында мәгълүматларны.»;

2.3 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Хезмәт ветераннарына субсидия-ташлама барлык кирәкле документлары белән гариза бирелгән айдан башлап билгеләнә һәм билгеләнгән айдан башлап алты ай дәвамында түләнә.

Мөрәҗәгать иткән көндә хезмәт ветераны субсидия алучы булса, субсидия-ташлама субсидия бирү вакыты тәмамланганга кадәр түләнә.

Әгәр хезмәт ветераны субсидия билгеләүне сорап мөрәҗәгать иткән граждан гаиләсе әгъзасы составына керә икән, субсидия билгеләү турында гариза белән бергә субсидия-ташлама билгеләү турында гариза да бирелергә мөмкин. Субсидия-ташлама субсидия алучы тапшырган гаилә кереме турында документларны исәпкә алып, субсидия алу чорында түләнә.

Үзәк бүлегендә хезмәт ветеранының субсидия-ташлама алуга хокукын раслый торган белешмәләр булганда, аңа яңа вакытка субсидия-ташлама хезмәт ветераны мөрәҗәгатеннән башка, автомат рәвештә билгеләнә.»;

түбәндәге эчтәлекле 2.3[1] пункт өстәргә:

«2.3[1]. Субсидия-ташлама билгеләү өчен уртача айлык керем хезмәт ветеранына барлык кирәкле документлары белән субсидия-ташлама билгеләү турында гариза тапшырган айга кадәрге соңгы алты календарь ай өчен билгеләнә (алга таба – исәп чоры).

Уртача айлык керем аның исәп чоры дәвамында алынган керемнәре суммасын ул әлеге керемнәрне алган бу исәп чоры айлары санына бүлү юлы белән билгеләнә.

Үзәк бүлекләренә Россия Федерациясе Пенсия фондыннан, шул исәптән бердәм ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасыннан һәм аңарга тоташтырылган төбәк ведомствоара электрон хезмәттәшлек системаларыннан файдаланып эш бирүче (иминиятләүче) физик зат файдасына күчергән түләүләр һәм бүтән бүләкләүләр суммасы турында мәгълүмат алу мөмкинлеген биргән мәгълүмати багланышларны керткәннән соң, хезмәт ветеранына субсидия-ташлама билгеләү аның гаризада күрсәтелгән ризалыгы белән, хезмәт ветераны субсидия-ташлама сорап мөрәҗәгать иткән айга кадәрге 12 айның соңгы алты аена Россия Федерациясе Пенсия фондында булган мәгълүматлар нигезендә башкарыла.»;

Әлеге Нигезләмәгә кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәгә кушымта

## Хезмәт ветеранына субсидия-ташламалар биргәндә исәпкә алына торган КЕРЕМНӘР ТӨРЛӘРЕ

1. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Уртача хезмәт хакын исәпләү тәртибе үзенчәлекләре турында» 2007 ел, 24 декабрь, 922 нче карары нигезендә уртача хезмәт хакын исәпләгәндә исәпкә алына торган, хезмәткә түләү системасында каралган барлык түләүләр;

хезмәт законнарында күздә тотылган очракларда сакланган уртача хезмәт хакы;

дәүләт яки иҗтимагый йөкләмәләрне башкарганда дәүләт органы яки иҗтимагый оешма түләгән компенсация;

эштән чыкканда түләнелә торган чыгу пособиесе, отставкага чыкканда компенсация, оешманың ябылуы, хезмәткәрләр саны яки штаты кимү белән бәйле эштән чыкканда эшкә урнашу чорына саклана торган эш хакы;

Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә төзелгән шартнамәләр буенча эшләргә түләү;

эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шөгыльләнүдән керемнәр, крестьян (фермер) хуҗалыгы, шул исәптән юридик зат оештырмаган хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәсендә алынган керемнәрне дә кертеп.

2. Барлык дәрәҗәдәге бюджетлардан социаль түләүләр:

пенсияләр, компенсация түләүләре (өстәмәләр, өстәп түләүләр);

пенсионерларны өстәмә айлык матди тәэмин итү;

ирекле иминиятләү шартларында түләнә торган өстәмә пенсияләр, дәүләтнеке булмаган пенсия фондларыннан түләнә торган пенсияләрне дә кертеп;

отставкага чыккан судьяларга айлык гомер буе түләнә торган акча;

ятим балаларга, ятим балалар арасыннан булган затларга, инвалид балаларга һәм инвалидларга стипендия;

эшсезлек буенча пособие;

матди ярдәм суммалары (эшсезләргә, студентларга, эшләүчеләргә);

һөнәри укыту яки яңадан укыту чорында алына торган стипендияләр суммалары;

эш белән тәэмин итү хезмәте органнары җибәрүе буенча иҗтимагый яки вакытлыча эшләрдә катнашкан гражданнарга аларның катнашу чорында законнарда каралган түләүләр (матди ярдәм);

14 яшьтән 18 яшькәчә балигъ булмаган гражданнарның вакытлыча эшләрдә катнашу чорында аларга түләүләр (матди ярдәм);

вакытлыча эшкә яраксыз булу буенча пособие;

җитештерүдәге бәхетсез очраклардан һәм һөнәри авырулардан мәҗбүри социаль иминиятләү буенча айлык иминият түләүләре;

оешмалар белән наем шартларында хезмәт мөнәсәбәтләрендә торган, бала тәрбияләү буенча ялда булган гражданнарга айлык компенсация түләүләре.

3. Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар билгеләгән бүтән социаль түләүләр, шул исәптән:

Чернобыль фаҗигасе сәбәпле нурланыш тәэсире яисә Чернобыль АЭСда авария нәтиҗәләрен бетерү буенча эшләр башкару белән бәйле гражданнар сәламәтлегенә китерелгән зыянны кайтаруга айлык акчалата компенсация;

хәрби хезмәткәрнең яки хәрби җыеннарга чакырылган гражданның хәрби хезмәт вазыйфаларын үтәгәндә вафат булуы (үлеме) яисә хәрби җәрәхәттән үлүе очрагында гаиләнең һәр әгъзасына түләнә торган айлык акчалата компенсация.».

3. 2016 елның 1 гыйнварына кадәр социаль ярдәм чаралары билгеләнгән хезмәт ветераннарына айлык акчалата түләү, субсидия-ташлама, элемтә хезмәтләренә субсидияләр бирү әлеге карар көченә кергәнче гамәлдә булган тәртиптә тормышка ашырыла дип билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының муниципаль районнары территориясендә урнашкан Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе учреждениеләре табиблары – яшь белгечләренә өстәмә социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» 2013 ел, 25 ноябрь, 923 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.

5. Бу карар 2016 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\911.docx